**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.06.2020 Балык Бистәсе штп. № 108пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 июнендәге 150п номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру Кагыйдәләре” нә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 2009 елның 27 декабрендәге 449-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына туры китерү максатларында, “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 2017 елның 31 декабрендәге 504-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 июнендәге 150п номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру Кагыйдәләре”нә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 02.02.2009 ел, №53пи, 24.03.2020 ел, №64п карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Ведомство контролен гамәлгә ашырганда ведомство контроле

органнары сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнарны үтәүне “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында " 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 99 маддәсенең 8 өлеше нигезендә тикшерә”;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының ”Сатып алулар һәм муниципаль контроль идарәсе” муниципаль казна учреждениесенә йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов